Чыгу көне: 30.12.2021

# Хуш киләсең, Яңа ел!

Кадерле дусларым! Яңа ел бәйрәме матур булып үтсен! Алдагы өр-яңа ел бары бәхет-куанычлар гына алып килсен. Туасы таңнар тыныч булсын. Гомер юлларыбыз шатлык белән тулып торсын һәрчак. Кызыклы очрашулар, бәхетле мизгелләр күп булсын! Укуыгызда уңышлар юлдаш булсын, күңелләрегездәге мәрхәмәтлелек бар җиһанны яктыртсын. Йортларыбызга авырулар, хәвеф-хәтәрләр, бәла-казалар килмәсен.

Йортларыгызда бәхет уты һәрвакыт сүнмичә янып торсын! Яңа ел белән

сезне, киләсе еллар бәхет китерүче еллардан булсын!

## Чыршы әйләнәсендә

Каршылыйк, дуслар, бергәләп:
Яңа ел килә безгә!
Әнә күпме кунак килгән
Әйләнә-тирәбезгә.

Йолдызлар төшеп кушылган
Чыршыдагы утларга.
Кыш бабай белән Кар кызы
Килгән безне котларга.

Кыш бабай килгәч, булачак
Котлаулар да, бүләк тә!

Яңа елда чыңга ашар
Безнең бөтен теләк тә!

Яңа елның бәхетле ел
Буласын без беләбез.
Шуңа күрә бергәләшеп
Яңа елга керәбез!

Рәхмәт сиңа да, иске ел!
Матур ел булдың бит син.
Синнән алган бәхет-шатлык
Гомер буена житсен!

Роберт Миңнуллин

## Чебоксарга бару хатирәләре

Мин Чебоксарга барудан алган тәэссирләрне беркайчан да онытмамын

**Бу чыгарылышта:**


| | |
|---|---|
| Яңа ел белән! | 1 |
| Мәктәп яңалыклары | 2-4 |


**Игътибар итегез!**

Кадерле укучылар!

Тиздән Яңа ел житә. Алда сезне каникуллар көтә. Хәзергә сезгә тырышып укырга, уку елын уңышлы тәмамларга кирәк!

Уңышлар сезгә!



шикелле...



Безне “61 нче урта гомум белем бирү мәктәбе”нең җитәкчеләре һәм укучылары бик җылы каршы алды. Шәһәр тарихы, мәдәнияты, халкы, гореф-гадәтләре белән таныштырдылар.

Туган ягыбыз белән таныштыруга корылган конференция бик кызык узды. Без “Этно-Хакатон”дигән яңа проект белән таныштык, башка халыклар белән очраштык.

Әхмәтҗанова Рузинә

Ел саен үткәрелә торган "**Хорлар көрәше**" фестивале безнең мәктәпнең традицион чарасына әйләнде. Фестиваль Татарстанда туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елының һәм РФ фән һәм технология елының йомгаклау вакыйгасы булды.

10 нчы де-



кабрь көнне 1-4 нче сыйныфлар өчен **“Сәламәтлек көне”** узды. Бөтен башлангыч сыйныф укучылары спорт киеменнән килгән иде.



Көн иртәнге зарядкадан башланды. Аннары күңелле старт һәм тематик сыйныф сәгатьләре, викторина, түгәрәк өстәл, интерактив уеннар уздырылды. Сәламәтлек көне һәр укучыга файдалы узды



# «Хәйрия »

1993 елдан 3 декабрь Халыкара инвалидлар көне итеп билгеләнде. Әлеге дата белән бәйле рәвештә декабрь башын инвалидлар декадасы итеп үткәрү традициягә керде. Мәктәбебез аларга ярдәм итеп, акция уздырды. Мәктәп укучылары, әти-әниләре, укытучылар аларга ярдәм йөзеннән яңа ел күчтәнәчләре, уенчыклар, мәктәп кирәк-яраклары алып килгән иде.

Инвалидлар турында без еш кына мөмкинлекләре чикле кешеләр дип әйтәбез. Ләкин алар арасында физик мөмкинлекләре чикле булса да, рух һәм йөрәк ныклыгы, ихтыяр көче булган кешеләр дә күп.



# Эшлекле әңгәмә



9 нчы декабрьдә безнең «Уңыш белән әңгәмә» мәктәп проектында реставрация һәм транспорт компаниясе хуҗасы Александр Михайлович Буров булды. Ул безгә үзенең уңышка юлы, сәламәт тәнне, рухны, акылны саклауның мөһимлеге турында сөйләде. Александр Михайловичтан төп киңәш: «Әгәр сез һөнәр сайлауда кыенсынсагыз, барысын да сынап карарга кирәк, һәм сез, һичшиксез, үзегезнекен табарсыз».

Редакциянең адресы:
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576
Тираж – 50 экз.

Баш мөхәррир һәм дизайнер: Габдуллаҗанова А.Ф.

Редколлегия әгъзалары: Сафина Камилла, Соколова София, Овезова Ләйлә, Курняева Юлия, Рузинә Әхмәтҗанова